Ботен ил буенча беренче авыл хужалыгы микропереписы (алга таба – СХМП-2021) старт алды. Бер ай – 1-30 август коннәрендә Росстат авыл хужалыгы продукциясен житештерvчеләр турында мәгълvмат жыячак. СХМП-2021 нигә vткәрелә, ул безнен тобәктә ничек узачак, анда кемнәр катнашачак, ни очен кирәк – бу һәм башка сорауларга безнен материалда жаваплар.
Исәпкә алучы ачык-яшел тостәге махсус киемгә киенеп йориләр: яктылык кайтаргыч полосалары булган жилет һәм кепка.   Жилетта да, кепкада да СХМП-2021 символикасы тошерелгән. Гамәлдәге чынбарлыкта исәпкә алучы образынын аерылгысыз атрибуты медицина битлеге, чонки эпидемиологик куркынычсызлыкнын барлык чараларын vтәп башкарыла. Яшел тостәге битлектә шулай ук СХМП-2021 символикасы да бар. Исәпкә алучы vзе белән паспорт кvрсәткәндә гамәлдә булган таныклык һәм планшет булырга тиеш.
Авыл хужалыгы исәбен алу алдына бары тик статистик бурычлар гына куела.
Авыл хужалыгы продукциясе житеш-терvчеләрнен торле категорияләре катнаша бу переписьтә. Мордовиядә 176 меннән артык объект, шул исәптән: 255 авыл хужалыгы оешмасы, 500 крестьян (фермер) хужалыгы һәм шәхси эшмәкәр, 175 206 шәхси ярдәмче һәм авыл жирендә яшәvче башка шәхси хужалыклар, 652 бакчачылык һәм яшелчәчелек коммерцияле булмаган ширкәтләре. Шәһәр жирлегендәге гражданнарнын шәхси хужалыклары һәм ишегаллары 10нан да ким булмаган торак пунктлар тикшерелмәячәк.
Беренче авыл хужалыгы санын алу яна технологик дәрәжәдә уза. Авыл хужалыгы оешмаларына, крестьян (фермер) хужалыкларына һәм шәхси эшмәкәрләргә электрон исәпкә алу кәгазьләрен мостәкыйль тутыралар. Моны Росстат web-жыю системасы яки махсус элемтә операторлары аша эшлиләр. Шулай ук исәпкә алу кәгазенен кәгазь вариантын тутыру момкинлеге дә саклана.
Авыл хужалыгы исәбен алу бары-шын оператив мониторинглау мәгъ-лvматлары буенча, Мордовия Республикасында 10 кон эчендә исәпкә алучылар 74 меннән артык (42,4%) хужалык хужаларыннан сорашып чыкканнар; гражданнарнын коммерцияле булмаган

бакчачылык һәм яшелчәчелек берләшмәләренен 20,9% буенча мәгълvмат алынган. Республиканын Инсар муниципаль районында исәпкә алучылар аеруча актив эшли. Алар vз районнарынын 58,3% турында мәгълvмат жыйганнар. Шулай ук лидерлар арасында Ичалково (шәхси ярдәмче хужалык хужаларынын 48,8% сораштырылган), Старошайгово (48,2%) һәм Ромоданово (47,7%) муниципаль районнары бар. Ромодановода ике татар авылында да исәп-хисап алып барыла. Мәсәлән, Алтар авылы администрациясе житәкчесе урынбасары Эльвина Камиль кызы Исхакова 380 Алтар йортынын һәм 2 КФХнын 48% мәгълуматны жыеп алган инде.
Ә Мордовиянен Рузаевка районы территориясендә 13 авыл хужалыгы оешмасы һәм предприятиесе, 17 крестьян (фермер) хужалыгы һәм шәхси эшмәкәр, авыл жирлекләрендә 8908 шәхси ярдәмче хужалык, 102 гражданнарнын бакчачылык һәм яшелчәчелек коммерцияле булмаган берләшмәләре микросан алу белән шогыльләнә. Гражданнарынын шәхси ярдәмче хужалыклары һәм коммерцияле булмаган оешмалары турында 19 исәпкә алучы жыя.
Татарларыбыз кvпләп яшәгән Ләмберә районы Аксен авылында ничегрәк микросан алу баруы турында администрациясе Айса Жәфәр улы Юсуповтан сорадым. Ул: “Районыбыз белән бергә, Аксен авылы администрациясенә кергән жирләрдә - Аксён һәм Иняты авылларында авыл хужалыгы микропереписын башлап жибәрдек. Ике авылда менгә якын хужалык, 11 фермер бар. Алар турындагы мәгълуматны һәм районыбызнын башка авылларындагысын Альфия Касим кызы Бәширова белән Эльвира Рәсим кызы Насырова жыялар. Халык аларны таный һәм аралаша.”
Авыл хужалыгы исәбен алу 2021 елнын 30 августында тогәлләнәчәк. Исәпкә алунын якынча нәтижәләре 2021 елнын IV кварталында ясалачак. Барлык жыелган мәгълvмат конфиденциаль характерда булачак, алар кызыксынган кулланучылар очен бары тик жыелма рәвештә генә басылып чыгачак.

Наилә НАСЫРОВА